ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 430-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 430-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 1993-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлектәге 3 өлешне өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Дәүләт хезмәткәре, федераль конституцион законнар яки федераль законнар белән башкача билгеләнмәгән очракта, акцияләренең (өлешләренең) 50 проценттан артыгы дәүләт корпорациясе, дәүләт компаниясе яки иҗтимагый-хокукый компания милкендә булган дәүләт корпорациясе, дәүләт компаниясе яки иҗтимагый-хокукый компания оешмасы булган коммерция оешмасы белән идарә итүдә, әлеге оешманың коллегиаль идарә органы әгъзасы буларак, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләүсез нигездә катнашырга хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктының «в» пунктчасы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән.

Күрсәтелгән нормага ярашлы рәвештә дәүләт граждан хезмәте узу сәбәпле дәүләт граждан хезмәткәренә, шул исәптән, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу тыела, федераль конституцион законнар яки федераль законнар белән башкача билгеләнмәгән очракта, акцияләренең (өлешләренең) 50 проценттан артыгы дәүләт корпорациясе, дәүләт компаниясе яки иҗтимагый-хокукый компания милкендә булган дәүләт корпорациясе, дәүләт компаниясе яки иҗтимагый-хокукый компания оешмасы булган коммерция оешмасы белән идарә итүдә, әлеге оешманың коллегиаль идарә органы әгъзасы буларак, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары яки Россия Федерациясе субъектының мондый катнашу тәртибен билгеләүче норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә түләүсез нигездә катнашудан тыш.

Күрсәтелгән көйләүгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең билгеләнгән оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу тәртибен билгеләү республикада нинди орган компетенциясенә керүен регламентлаштырырга кирәк.

Закон проекты белән күрсәтелгән вәкаләтне, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында чагылдырып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты компетенциясенә кертергә тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең акцияләренең (өлешләренең) 50 проценттан артыгы дәүләт корпорациясе, дәүләт компаниясе яки иҗтимагый-хокукый компания милкендә булган дәүләт корпорациясе, дәүләт компаниясе яки иҗтимагый-хокукый компания оешмасы булган коммерция оешмасы белән идарә итүдә, әлеге оешманың коллегиаль идарә органы әгъзасы буларак, түләүсез нигездә катнашу тәртибен җайга салучы карар чыгару таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акча бүлеп бирүне таләп итмәячәк.